ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

№ 319 2017 елның 12 мае

# Субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү өчен, Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» Дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» Дәүләт программасының «2014-2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасы, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 декабрендә кабул ителгән 1740 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм һәм аны үстерү» муниципаль программасы нигезендә, карар бирәм:

1. Әлеге карарның кушымтасына ярашлы рәвештә субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. И. Беляевка йөкләргә.

А. Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 12 маендагы
319 номерлы карары белән расланган
кушымта

Субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү өчен,
Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Субсидияләр формасында ярдәм күрсәтү өчен, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алуның әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) субсидияләр формасында ярдәм күрсәтү максатларын, шартларын һәм тәртибен, шулай ук, субсидияләр формасында ярдәм күрсәтү өчен, Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу категориясен һәм критерийларын билгели.

1.2. Муниципаль берәмлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» Дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» Дәүләт программасының «2014-2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыруга әлеге финанс елы һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган муниципаль берәмлеккә Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган акчалар исәбенә конкурентлы икътисадый мохит үсешендә кече һәм урта эшкуарлыкның ролен арттыру максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 декабрендә кабул ителгән 1740 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм һәм аны үстерү» муниципаль программасы белән каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә башкарыла.

1.3. Муниципаль берәмлек кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субсидия (алга таба – субсидия) рәвешендә ярдәм түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру кысаларында бирелә:

1) җиһазлар лизингын үстерү: җиһазлар лизингы шартнамәсе буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары чыгымнарын субсидияләү («ЛИЗИНГ-ГРАНТ»);

2) Татарстан Республикасының социаль эшкуарлыгын үстерү.

1.4. Әлеге тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән чаралар кысаларында дәүләт ярдәме күрсәтү өчен кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу әлеге

тәртиптә билгеләнгән шартлар һәм сроклар нигезендә ярдәм күрсәтү өчен муниципаль берәмлекнең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе утырышларында башкарыла.

1.5. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (алга таба – эшмәкәрлек субъектлары) – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән шартлар нигезендә, кече предприятиеләргә, шулай ук микропредприятиеләргә һәм урта предприятиеләргә кертелгән хуҗалык итүче субъектлар (юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр);

Бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче (алга таба - Вәкаләтле орган) - кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсендә җайга салуны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты;

Интернет мәгълүмәт-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле орган сайты - www.e-nkama.ru;

Вәкаләтле оешма – Вәкаләтле орган белән үзара хезмәттәшлек турында килешү төзегән «Татарстан Республикасы эшкуарлыкка ярдәм итү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен төзү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 4 мартындагы 132 номерлы карары нигезендә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

муниципаль берәмлек - Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре;

социаль эшкуарлык - социаль проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларының социаль җаваплы эшчәнлеге;

гариза бирүче - әлеге тәртип таләпләре нигезендә субсидия алу хокукына ия булган эшкуарлык субъектларын билгеләү буенча конкурс сайлап алуында катнашуга конкурс гаризасын биргән Татарстан Республикасы эшкуарлык субъекты;

конкурс гаризасы-конкурс сайлап алуында катнашу өчен әлеге тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән документлар;

эшкуарлыкны башлап җибәрүче субъект – аны теркәү вакыты конкурс гаризасын бирү вакытына алты айдан артык, әмма бер елдан да ким булмаган вакыт аралыгын тәшкил итә торган эшкуарлык субъекты;

эшкуарлыкның гамәлдәге субъекты - аны теркәү срогы конкурс гаризасын бирү вакытына бер елдан артык тәшкил итә торган эшкуарлык субъекты;

конкурс сайлап алуы – субсидия алу хокукына ия эшкуарлык субъектларын билгеләү процедурасы;

конкурс комиссиясе - гариза бирүчеләрнең конкурс гаризаларын карау һәм әлеге тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча субсидия алу хокукына ия эшкуарлык субъектларын билгеләү өчен Вәкаләтле орган тарафыннан төзелгән комиссия;

конкурс гаризасы - конкурс сайлап алуында катнашу өчен әлеге Тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән документлар;

Конкурс комиссиясе әгъзалары булып, сайлап алу нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынган затлар (шул исәптән конкурс сайлап алуында катнашу өчен конкурс гаризасын биргән яки күрсәтелгән конкурс гаризаларын биргән оешмалар штатында торучы), яисә конкурс сайлап алуында катнашучылар йогынты ясарга сәләтле затлар (шул исәптән гариза бирүчеләрнең катнашучылары (акционерлары), аларның идарә итү органнары әгъзалары, гариза бирүчеләрнең кредиторлары булган физик затлар) була алмый;

субсидия алучы - аның буенча Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгнән эшкуарлык субъекты;

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы (алга таба – сәнәгать мәйданчыгы) – аның чикләрендә яңа җитештерүләр булдыру һәм үстерү өчен уңай шартлар тудырыла торган, бердәм чиккә ия булган, 20 мең кв. метрдан ким булмаган җир кишәрлегендә урнашкан, бердәм оператор (идарәче компания) идарә итә торган барлык милек формалы күчемсез милек объектларының аерымланган территориаль комплексы;

сәнәгать мәйданчыгы резиденты - сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген алып баручы эшкуарлык субъекты;

режимлы объектның җитештерү мәйданчыгы - җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә караган режимлы объект территориясендә урнашкан җитештерү мәйданчыгы;

режимлы объектның җитештерү мәйданчыгы резиденты - режимлы объектның җитештерү мәйданчыгы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген башкаручы эшкуарлык субъекты;

җиһаз – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Амортизация төркеменә кертелә торган төп чараларны классификацияләү турында» 2002 елның 1 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган амортизация төркемнәренә кертелә торган төп чараларны классификацияләү төркемнәренең икенче һәм аннан югары амортизация төркемнәренә керә торган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының күпләп һәм ваклап сату эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җиһазлардан һәм элек эксплуатацияләнгән җиһазлардан тыш, җиһазлар, җайланмалар, механизмнар, транспорт чаралары (җиңел автомобильләрдән һәм һава судноларыннан тыш), станоклар, приборлар, аппаратлар, агрегатлар, установкалар, машиналар;

Порталда шәхси бүлмә - Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында uslugi.tatarstan.ru гариза бирүченең шәхси бүлмәсе;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (алга таба - Портал) - дәүләт хакимияте органнары һәм ведомствога караган оешмалар, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр, шулай ук электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр турында белешмәләр тупланган Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://uslugi.tatarstan.ru сайт рәвешендәге белешмә-мәгълүмати интернет-портал;

мәгълүмат системасы –Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү чараларын

күрсәтүгә вәкаләтле оешмалар эшчәнлеген автоматлаштыру, шулай ук ведомствоара бәйләнештә катнашу процессларын мәгълүмати тәэмин итү өчен билгеләнгән «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү» дәүләт мәгълүмати-аналитик системасы;

электрон култамга – электрон формада башка мәгълүматка (кул куела торган мәгълүмат) тоташтырылган яки башка рәвешле мондый мәгълүмат белән бәйле һәм ул мәгълүматка имза салучы затны билгеләү өчен кулланыла торган электрон формада мәгълүмат;

гади электрон култамга - кодлар, парольләр яки башка чараларны куллану ярдәмендә билгеле бер зат тарафыннан электрон култамга формалаштыру фактын раслый торган электрон култамга.

2. Субсидия алуга дәгъва кылучы мөрәҗәгать итүчеләргә карата таләпләр

2.1. Эшкуарлык субъекты бер үк вакытта түбәндәге шартларны үтәгәндә субсидия алуга дәгъва итә ала:

2.1.1. Эшкуарлык субъекты гариза бирү вакытына:

а) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен билгеләнгән таләпләргә туры килә:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы;

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары;

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының һәр категориясе өчен эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырудан алынган керемнең иң чик күләмнәре турында» 2016 елның 4 апрелендәге 265 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;

б) хуҗалык итүче субъект (юридик зат яки шәхси эшмәкәр) буларак алты айдан артык теркәлгән;

в) Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып бара;

г) эшкуарлык субъектының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр, шулай ук Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри пенсия һәм медицина иминияте өчен иминият кертемнәре буенча үтәлмәгән бурычы юк;

д) эшкуарлык субъектының әлеге тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча элегрәк алынган ярдәмгә бәйле рәвештә үтәлмәгән бурычы юк, шул исәптән акчалардан файдалану турында һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү турында хисап бирү буенча;

е) эшкуарлык субъекты эшчәнлегенең төп яисә өстәмә төрләренең берсе булып, акциз товарларын җитештерү һәм сату, шулай ук, гомумтаралган файдалы казылмалардан тыш, файдалы казылмалар чыгару һәм сату тормый.

2.2. Субсидия бирү өчен шартнамә төзү планлаштырыла торган айның алдыннан килгән айның беренче числосына карата:

а) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үтәү вакыты килеп җиткән мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминият кертемнәре буенча бурычлары юк;

б) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләре, һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджет системасы каршындагы башка срогы чыккан бурычларны кайтару буенча вакытында түләнмәгән башка бурычлары юк;

в) үзгәртеп кору, гамәлдән чыгару, банкротлык процессында тормый һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләр юк;

г) чит ил юридик заты, шулай ук аның устав (җыелма) капиталында салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яисә) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен (офшор зоналар) үткәргәндә, мәгълүматны ачу һәм бирүне күздә тотмый торган, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган дәүләт һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булган, чит ил юридик заты катнашу өлеше тулаем алганда 50 процентtан артып киткән Россия юридик заты булып тормый;

д) әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча башка норматив хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмый.

3. Субсидия алуга документлар әзерләү

3.1. Конкурс сайлап алуында катнашу өчен эшкуарлык субъекты әлеге Тәртип таләпләренә туры китереп рәсмиләштерелгән конкурс гаризасын тапшырырга тиеш.

3.1.1. Конкурс гаризасы кәгазьдә яисә электрон рәвештә («җиһаз лизингын үстерү: кече һәм урта эшкуарлык субъектларының җиһаз лизингы шартнамәсе («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә киткән чыгымнарын субсидияләү» чарасы буенча конкурс гаризалары бирүче эшкуарлык субъектлары өчен) Порталда гариза бирүченең шәхси кабинеты аша тапшырылырга мөмкин.

3.2. Гариза бирү барышында һәм шартнамә төзү максатларында тапшырыла торган барлык документлар, шул исәптән Портал аша бирелә торган документлар төгәл бастырып чыгарылырга һәм барлык пунктлары тутырылырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта сызык куела). Чистарту һәм төзәтүләр, мөһере белән беркетелгән (Россия Федерациясе законнары белән мөһер булу бурычы билгеләнгән очракларда) һәм вәкаләтле затның (юридик затлар өчен) имзасы белән расланган яисә үз кулы белән расланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) төзәтмәләрдән тыш, рөхсәт ителми. Кәгазь чыганакта бирелгән конкурс гаризасының барлык битләре дә номерланырга тиеш. Кәгазь чыганакта бирелгән документларның күчермәләре вәкаләтле затның имзасы һәм эшмәкәрлек субъекты мөһере (юридик затлар өчен) белән (Россия Федерациясе законнары белән мөһер булу бурычы билгеләнгән очракларда) яисә үз кулы белән (шәхси эшмәкәрләр өчен) таныкланырга тиеш. Портал аша сканерланган күчермәләр рәвешендә бирелгән

документлар вәкаләтле затның гади электрон имзасы белән таныкланырга тиеш. Кәгазьдә бирелгән конкурс гаризасы тегелгән һәм, конкурс гаризасы битләренең гомуми санын күрсәтеп, конкурс гаризасының арткы ягында вәкаләтле затның имзасы һәм эшкуарлык субъекты мөһере (юридик затлар өчен) белән (Россия Федерациясе законнары белән мөһер булу бурычы билгеләнгән очракларда) яисә үз кулы белән (шәхси эшмәкәрләр өчен) таныкланган булырга тиеш.

3.3. Конкурс заявкасы составында кирәкле документларның булмавы, әлеге Тәртипнең 3.2 пункты белән билгеләнгән конкурс гаризасын рәсмиләштерүгә карата таләпләрне бозу, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларда эшкуарлык субъекты тарафыннан әлеге Тәртипнең 2.1. пунктында каралган шартларның үтәлешен раслый торган белешмәләрнең булмавы, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларда 7.3 пунктында каралган икътисадый эшчәнлек төрләре төркемнәре һәм төркемчәләре буенча эшчәнлекнең төп һәм (яисә) өстәмә төрләрен гамәлгә ашыруны раслый торган белешмәләрнең булмавы, яки эшкуарлык субъекты тарафыннан әлеге Тәртипнең 8.3 пунктында каралган шартларның берсен үтәве, тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы, эшкуарлык субъектын конкурс нигезендә сайлап алуда катнашучылар арасына кертүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

3.4. Конкурс гаризасын әзерләү буенча барлык чыгымнарны эшмәкәрлек субъекты үз өстенә ала.

3.5. Әлеге Тәртип турында һәм Әлеге Тәртип нигезендә тутырылырга тиешле документларның формалары турында мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле орган сайтында урнаштырыла.

4. Конкурс гаризасы составында документлар исемлеге

4.1. Конкурс гаризасы үз эченә түбәндәге документларны ала:

вәкаләтле затның имзасы һәм эшмәкәрлек субъекты мөһере (юридик затлар өчен) белән (Россия Федерациясе законнары белән мөһер булу бурычы билгеләнгән очракларда) яисә үз кулы белән (шәхси эшмәкәрләр өчен) расланган әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә субсидия бирүгә гариза;

шәхси эшмәкәр яки юридик зат җитәкчесе паспортының тутырылган битләренең күчермәләре;

бухгалтерлык хисаплылыгы (бухгалтерлык балансы һәм финанс нәтиҗәләре турында хисап) (хисапны кабул итү турында салым органы тамгасы белән яки тиешле органның вазыйфаи затының электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвештә хисапны кабул итү һәм тикшерү турындагы документлар теркәп тапшырыла) яки керемнәрне һәм чыгымнарны исәпкә алу кенәгәсе (бухгалтерлык исәбен алып бармаган эшкуарлык субъектлары өчен, «Бухгалтерлык хисабы турында» 2011 елның 6 декабрендә кабул ителгән 402-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә), агымдагы хисап чорында теркәлгән соңгы хисап датасына ( юридик затлардан (шәхси эшкуарлардан) башка);

салым декларациясе (хисапны кабул итү турында салым органы тамгасы белән яисә хисапны тиешле органның вазыйфаи затының электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвештә кабул итү һәм тикшерү турындагы документларны

теркәп тапшырыла), теркәлгән соңгы хисап датасына (агымдагы хисап чорында теркәлгән эшкуарлык субъектларыннан тыш);

«Иминиятләштерелгән затлар турында мәгълүматлар» формасын раслау турында» Россия Федерациясе Пенсия фонды идарәсенең 2016 елның 1 февралендәге 83п номерлы карары белән расланган форма буенча иминиятләштерелгән затлар турында белешмәләр (кабул итү турында пенсия фонды органнарының тамгасы белән яисә электрон цифрлы имза белән имзаланган хисапны кабул итү һәм тикшерү турындагы документларны теркәп бирелә), соңгы хисап датасына (агымдагы хисап чорында теркәлгән эшкуарлык субъектларыннан тыш);

гамәлгә куючы документлар (юридик затлар өчен);

Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2007 елның 29 мартындагы ММ-3-25/174@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча узган календарь елында хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны турында белешмәләр (салым органының кабул итү турында тамгасы белән яисә электрон цифрлы имза белән имзаланган хисапны кабул итү һәм тикшерү турындагы документларны теркәп бирелә), соңгы хисап датасына (агымдагы хисап чорында теркәлгән эшкуарлык субъектларыннан тыш);

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә мөрәҗәгать итүченең әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында вәкаләтле вәкил имзасы һәм эшкуарлык субъекты мөһере (юридик затлар өчен) белән таныкланган (Россия Федерациясе законнары белән мөһер булу бурычы билгеләнгән очракларда) яисә үз кулы белән (шәхси эшмәкәрләр өчен) расланган гарантия хаты;

субсидия бирү максатларына бәйле рәвештә, әлеге Тәртипнең 7.6., 8.6. пунктларда каралган документлар.

Чит телдәге документларны гариза бирүче билгеләнгән тәртиптә расланган аларның рус теленә тәрҗемәсе белән бергә тапшыра.

4.2. Мөрәҗәгать итүченең әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе конкурс гаризасы составында тапшырыла торган документлар, шулай ук түбәндәге документларда булган мәгълүмат нигезендә билгеләнә:

эшмәкәрлек субъектын дәүләт теркәве турында документ (ОГРН);

эшкуарлык субъектын салым исәбенә кую турында документ (ИНН);

Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2014 елның 21 июлендәге ММВ-7-8/378@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча конкурс гаризасы бирелә торган айның беренче числосына бирелгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентларны түләү буенча эшкуарлык субъектында үтәлмәгән йөкләмәнең булмавын раслаучы салым органы белешмәсе;

Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрыннан конкурс гаризасын бирү датасына кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк бирелмәгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган өземтә;

Вәкаләтле оешма әлеге документларны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә ала.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук Вәкаләтле оешмага әлеге пунктта күрсәтелгән документларның тиешле расланган күчермәләрен тапшырырга хокуклы.

4.3. Тапшырыла торган белешмәләрнең дөрес булмавы өчен мөрәҗәгать итүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

5. Конкурс гаризаларын кабул итү һәм карау

5.1. Гаризалар Вәкаләтле оешма тарафыннан кабул ителә.

Конкурс гаризаларын кабул итү чоры Вәкаләтле орган карары белән билгеләнә һәм 14 эш көненнән дә ким булмаска тиеш. Конкурс гаризаларын кабул итү чоры турында мәгълүмат конкурска гаризалар кабул итә башлаганчыга кадәр эш көннәрендә санала торган 3 көнлек срокта Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында бастырыла.

Вәкаләтле оешма тарафыннан конкурс гаризаларын кабул итү нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән бирелгән бюджет ассигнованиеләрен бүлгән очракта гамәлгә ашырылмый.

Вәкаләтле орган конкурс гаризаларын кабул итүне түбәндәге очракларда яңадан башлап җибәрә:

агымдагы елда Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яисә) федераль бюджет акчалары исәбеннән чараларны гамәлгә ашыруга өстәмә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү;

әлеге Тәртипнең1.2 пунктта күрсәтелгән бюджет ассигнованиеләрен тулысынча бүлмәү;

субсидия алучылардан субсидияләр алудан баш тартуы (шәхси гариза нигезендә яки әлеге Тртипнең 6.2 пункт таләпләре нигезендә).

Гаризалар кабул итүнең яңартылуы турында мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Вәкаләтле органның рәсми сайтында конкурс гаризаларын кабул итү яңартылган көнгә кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

5.2. Конкурс гаризасы Вәкаләтле оешма тарафыннан мәгълүмат системасына кергән көнне теркәлә.

5.3. Мәгълүмат системасында теркәлгән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнүче 10 көнлек срокта конкурска гаризалар Вәкаләтле оешма тарафыннан әлеге Тәртиптә куелган таләпләргә туры килү-килмәвенә тикшерелә.

Конкурс гаризасын тикшерү нәтиҗәләре турында Вәкаләтле оешма эшмәкәрлек субъектына хәбәрнамә җибәрә. Хәбәрнамә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тикшерү срогы чыккан көннән соң өченче эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелергә тиеш.

Портал аша гариза биргән гариза бирүчеләргә тикшерү нәтиҗәләре турында Порталда гариза бирүченең шәхси кабинеты аша хәбәр ителә.

Вәкаләтле оешма тарафыннан әлеге тәртип таләпләренә туры килә торган конкурс гаризаларына «SWOT-анализ» стратегик планлаштыру ысулын кулланып резюме әзерләнә.

5.4. Конкурс сайлап алуына конкурс гаризасын кертү турында мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Вәкаләтле органның рәсми сайтында конкурс комиссиясенең чираттагы утырышын үткәрүгә 3 эш көне кала

урнаштырыла.

5.5. Конкурс сайлап алу Вәкаләтле орган тарафыннан ачык рәвештә башкарыла.

5.6. Вәкаләтле орган конкурс комиссиясе утырышын үткәрү датасы һәм вакыты турында мәгълүматны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Вәкаләтле органның рәсми сайтында утырыш уздырылган көнгә кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча бастыра.

5.7. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның исемлек составының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы.

5.8. Конкурс комиссиясе утырышының халык өчен ачыклыгы Вәкаләтле органның рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә онлайн-трансляция уздыру юлы белән тәэмин ителә.

5.9. Конкурс гаризалары конкурс комиссиясе утырышында юридик зат-мөрәҗәгать итүче җитәкчесе яки индивидуаль эшкуар-мөрәҗәгать итүче яисә закон нигезендә рәсмиләштерелгән нотариаль ышанычнамә нигезендә аларның вәкиле катнашында карала. Конкурс гаризалары, конкурс сайлап алуына кертелгән беренче конкурс гаризасыннан башлап, берәрләп, мәгълүмати системада гаризалар реестры нигезендә карала.

Юридик зат-мөрәҗәгать итүче җитәкчесе яисә индивидуаль эшкуар-мөрәҗәгать итүче яисә аларның вәкиленең килүе мәҗбүри дип танылa. Алар килмәгән очракта, конкурс гаризасын карау үткәрелми һәм субсидия бирүдән баш тарту турында конкурс комиссиясе карары чыгарыла.

5.10. Җиһаз лизингы («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») шартнамәсе буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә кече һәм урта эшкуарлык субъектларының чыгымнарын субсидияләүгә хокукы булган эшкуарлык субъектларын билгеләгәндә, конкурс комиссиясе әгъзалары сайлап алу конкурсының түбәндәге критерийларына таяна:

| | | |
|---|---|---|
| | Проектны эшләү дәрәҗәсе | 1-5 балл |
| | Проектны тормышка ашыруның икътисадый нәтиҗәлелеге | 1-5 балл |
| | Социаль-икътисадый күрсәткечләргә ирешү | 1-5 балл |
| | Ихтыяҗ | 1-5 балл |
| | Импортны алыштыру | 1-5 балл |

Социаль эшкуарлыкны үстерү өчен субсидияләр алу хокукына ия эшкуарлык субъектларын билгеләгәндә конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска сайлап алуның түбәндәге критерийларга таяна:

| | | |
|---|---|---|
| | Проектны эшләү дәрәҗәсе | 1-5 балл |
| | Проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте | 1-5 балл |

| | | |
|---|---|---|
| | Конкурентлык | 1-5 балл |
| | Ихтыяҗ | 1-5 балл |
| | Икътисадый максатка ярашлылык | 1-5 балл |

5.11. Конкурс комиссиясе әгъзалары 5 баллы шкала буенча (1 дән 5 кә кадәр) конкурс сайлап алуының һәр критерие буенча таләпләр белән конкурс гаризаларын бәялиләр.

Өстәмә балл Россия Саклык банкы тарафыннан Google компаниясе белән берлектә гамәлгә ашырыла торган «Бизнес-класс» белем бирү проекты кысаларында белем алу турында сертификат тапшырган эшмәкәрлек субъектларына исәпләнә.

Өстәмә балл эш урыннары буенча максатчан күрсәткечкә 4 берәмлектән артык ирешүне планлаштыручы эшкуарлык субъектларына исәпләнә.

Конкурс комиссиясе, конкурс гаризалары 12 баллдан да ким булмаган балл алудан чыгып, эшкуарлык субъектларының субсидияләр алу хокукына ия булу-булмавын билгели. Шул ук вакытта уңай карала торган гаризалар саны Конкурс комиссиясе тарафыннан Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 декабрендәге 1740 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү» муниципаль программасында каралган бюджет ассигнованиеләренең бүлеп бирелгән лимитларыннан чыгып, бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә билгеләнә.

5.12. Конкурс гаризаларын карау нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге карарлар чыгара:

бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендә булган субсидия алу хокукына ия булган катнашучыларны билгеләү турында;

бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендә булмаган субсидия алу хокукына ия булган катнашучыларны билгеләү турында;

субсидия алу хокукына ия булмаган катнашучыларны билгеләү турында.

5.13. Конкурс комиссиясе карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аны конкурс комиссиясе секретаре алып бара. Беркетмә конкурс комиссиясе утырышын үткәрү көнендә конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

5.14. Беркетмәдә конкурс комиссиясе утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары, каралган гаризаларның саны, эшкуарлык субъекты теркәлгән муниципаль берәмлек һәм эшкуарлык субъекты дәгъва итә торган субсидия суммасын күрсәтеп, конкурс гаризаларын карау нәтиҗәсе, субсидия бирүдән баш тарткан катнашучылар буенча субсидияләр суммасы турында мәгълүмат урнаштырылган.

5.15. Беркетмә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында, расланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көнлек срокта урнаштырыла.

5.16. Портал аша гариза биргән гариза бирүчеләргә конкурс нәтиҗәләре турында порталда гариза бирүченең шәхси кабинеты аша өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

5.17. Мөрәҗәгать итүче билгеләнгән тәртиптә яңа конкурс гаризасы белән

мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.18. Гариза бирүче тарафыннан Портал аша бирелгән гаризалар Вәкаләтле оешмада һәм Вәкаләтле органда электрон рәвештә саклана.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакта бирелгән гаризалар Вәкаләтле органда саклана. Мөрәҗәгать итүче кәгазь чыганакта үзе тапшырган документларны соратып алырга хокуклы.

## 6. Субсидияләр бирү тәртибе

6.1. Субсидия бирү өчен нигез булып, әлеге тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә субсидия бирү турында Вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында төзелә торган шартнамә (алга таба - шартнамә) тора.

Шартнамәдә субсидияләр күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлеше, субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре (максатчан күрсәткечләр), субсидияләрне күчерү тәртибе, субсидиядән файдалану турында хисап бирү һәм субсидияләрдән (максатчан күрсәткечләрдән) файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү тәртибе, сроклары һәм формалары, агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыкларын кире кайтару очраклары, алынган акчалар исәбенә чит ил валютасы сатып алуны тыю турында нигезләмә, югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлау эшләнмәләрен сатып алганда (җибәргәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү максатына ирешү белән бәйле бүтән операцияләрдән тыш, Вәкаләтле орган, Вәкаләтле оешма һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен, субсидия алучының әлеге Тәртипнең һәм төзелә торган шартнамәнең шартларын үтәүләре турында нигезләмәнең үтәлешен тикшерүне башкаруга ризалыгы күрсәтелә.

6.2. Әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының 1-2 пунктчаларында күрсәтелгән чаралар буенча эшмәкәрлек субъекты Беркетмә расланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнелә торган 30 көнлек срокта әлеге Тәртип таләпләре нигезендә субсидия бирү турында шартнамә төзү өчен Вәкаләтле органга документлар тапшыралар.

Шартнамә төзү өчен кирәкле документлар әлеге Тәртипнең 3.2 пункты нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш.

Эшкуарлык субъекты тарафыннан әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәгән очракта, Конкурс комиссиясе тарафыннан чыгарылган уңай карар юкка чыгарылган дип санала.

6.3. Шартнамә төзү өчен кирәкле документлар Вәкаләтле орган тарафыннан аларның мәгълүмат системасына кергән көнендә теркәлә.

Шартнамә төзү өчен кирәкле документларның сканерланган күчермәләре гариза бирүченең Порталдагы шәхси кабинеты аша («җиһаз лизингын үстерү: кече һәм урта эшкуарлык субъектларының җиһаз лизингы килешүе («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә киткән чыгымнарын субсидияләү» чарасы буенча субсидия алуга дәгъва кылучы эшкуарлык субъектлары өчен) электрон рәвештә алдан тикшерү өчен җибәрелергә мөмкин.

Шартнамә төзү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта килешү төзү өчен кирәкле документлар Вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртиптә күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү предметына тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре турында Вәкаләтле орган эшмәкәрлек субъектына хәбәрнамә җибәрә. Хәбәрнамә тикшерү вакыты чыккан көннән соң өченче эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелергә тиеш.

Документлар тәртип таләпләренә тулысынча туры килсә, Вәкаләтле орган тикшерү вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көнлек срокта субсидия бирү турында карар кабул итә.

Карарда карар чыгарылган дата, вакыты һәм урыны, карар чыгарыла торган эшмәкәрлек субъекты исеме, бирелә торган субсидия суммасы турында мәгълүмат була.

Җитешсезлекләр булган очракта, эшкуарлык субъектына аларны әлеге Тәртипнең 6.2 пунктының беренче абзацында билгеләнгән вакыт эчендә төзәтү хокукы бирелә. Аларны бетермәгән очракта, Конкурс комиссиясе тарафыннан чыгарылган карар гамәлдән чыгарылган дип санала.

6.4. Вәкаләтле орган һәм Вәкаләтле оешма, шартнамә төзү өчен субсидия алучыга карата әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрдән тыш, башка таләпләр куя алмый.

6.5. Вәкаләтле орган субсидиянең максатчан кулланылышы һәм шартнамәдә күрсәтелгән максатчан күрсәткечләргә ирешү турында мәгълүмат бирүне контрольдә тота.

6.6. Субсидиядән файдалану турында хисап эшмәкәрлек субъекты тарафыннан Вәкаләтле органына бирелә.

Субсидиядән файдалану турында хисап формалары, хисап бирү тәртибе һәм сроклары шартнамәдә билгеләнә.

6.7. Вәкаләтле органның шартнамәгә үзгәрешләр кертү белән бәйле карарлары дәүләт ярдәме алган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бизнес-проектларын гамәлгә ашыру барышында барлыкка килгән мәсьәләләрне карау буенча Комиссия утырышлары беркетмәләре нигезендә кабул ителә. Күрсәтелгән комиссиянең составы һәм аның эш тәртибе Вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

6.8. Субсидияләр Вәкаләтле орган тарафыннан, бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары керү срокларын һәм чикләрен исәпкә алып, шартнамә төзү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнгән 10 көнлек срокта Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучыга ачылган алучының хисап счетына акча күчерү юлы белән бирелә.

Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган акчалар торган юридик затлар чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен муниципаль берәмлек бюджетыннан бирелә торган субсидияләр белән операцияләр муниципаль берәмлекнең финанс органы мөрәҗәгате нигезендә Федераль казначылыкның территориаль органнарында күрсәтелгән субсидияләрне алучы юридик затларга ачыла торган шәхси счетларда чагылырга тиеш. Субсидия алучыга, бюджет процессында катнашмаган юридик затлар (аларның аерым бүлекчәләре) акчалары белән

операцияләрне исәпкә алу өчен, Федераль казначылыкның территориаль органында шәхси счет ачыла. Субсидия алучының акчалата йөкләмәсен түләү өчен Федераль казначылыкның территориаль органына субсидия алучы тарафыннан түләү документларын тапшырганнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча күчерелә.

6.9. Бирелгән субсидияләр, субсидия алучы тарафыннан Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көн эчендә муниципаль берәмлек бюджеты кеременә түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучының әлеге Тәртип һәм шартнамәдә билгеләнгән шартларны бозу фактларын ачыклаганда;

Вәкаләтле оешма һәм Вәкаләтле органга документларда күрсәтелгән дөрес булмаган белешмәләр биргәндә;

календарь ел нәтиҗәләре буенча шартнамәдә каралган бизнес-проектны гамәлгә ашыруның максатчан күрсәткечләренең 20% тан артыграгы үтәлмәгәндә.

Хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан файдаланылмаган субсидияләр калдыгы булган очракта, субсидияләрнең калган өлеше хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр муниципаль берәмлек керемено кире кайтарылырга тиеш.

Вәкаләтле орган һәм финанс контроле органнары субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен законнар белән билгеләнгән тәртиптә үтәүләрен тикшерә.

Субсидия алучы тарафыннан субсидия акчаларын кире кайтару өчен билгеләнгән срокны бозганда, Вәкаләтле орган, әлеге пунктның беренче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән сроклар тәмамланганнан соң, календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләрне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кире кайтару буенча чаралар күрә.

6.10. Субсидияләрнең максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын контрольдә тоту гамәлдәге законнар нигезендә Вәкаләтле орган һәм финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.11. Мөрәҗәгать итүче Вәкаләтле органның һәм вәкаләтле оешманың вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

7. Җиһаз лизингын үстерү:

җиһаз лизингы шартнамәсе (ЛИЗИНГ-ГРАНТ) буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары чыгымнарын субсидияләү.

7.1. Чараның максаты - эшкуарлык субъектларының җиһаз лизингы шартнамәсе буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә чыгымнарын субсидияләү.

Финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча беренче кертем (аванс) - лизинг түләүләрен түләү графигында билгеләнгән һәм лизинг предметын мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты буенча фактта алган мизгелгә кадәр эшкуарлык субъекты тарафыннан финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча гамәлгә ашырыла торган түләү (түләүләр).

7.2. Субсидияләр лизинг шартнамәләрен төзегән һәм икътисадый эшчәнлекнең өстенлекле төрләрендә бизнес-проектларны гамәлгә ашыручы эшкуарлык субъектларына бирелә.

Лизингка бирүче белән лизинг шартнамәсе конкурс гаризасын биргән вакытка гамәлдә булырга тиеш.

7.3. Лизингка бирүче – читтән җәлеп ителгән яки үз акчалары хисабына лизинг шартнамәсен гамәлгә ашыру барышында милеккә җиһаз сатып ала торган һәм аны эшкуарлык субъектына лизинг предметы сыйфатында бирә торган юридик зат. Лизинг бирүче түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

а) Россия Федерациясе резиденты статусы булу;

б) мөлкәтне төп эшчәнлек төре буларак финанс арендасына (лизингка) бирүне гамәлгә кую документларында күрсәтү;

в) эшкуарлык субъектларына мөлкәтне финанс арендасына (лизингка) бирү өлкәсендә кимендә өч ел эш тәҗрибәсе булу;

г) эшкуарлык субъектлары белән төзелгән финанс арендасы (лизинг) шартнамәләренең формалаштырылган портфеле булу, эшкуарлык субъектлары белән эшләү өчен махсус технологияләр (программалар) булу;

д) лизинг алучының - эшкуарлык субъектының финанс хәлен бәяләүнең расланган методикасы булу;

е) соңгы хисап көненә чиста активлар хакының уңай күләме булу («Чиста активлар бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 28 августындагы 84н номерлы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган методика буенча);

ж) соңгы хисап датасына чиста активларның бәясе 40 млн сумнан («Чиста активлар бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 28 августындагы 84н номерлы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган методика буенча), яисә соңгы хисап көненә устав капиталының күләме 15 млн сумнан да ким булмаска тиеш, яисә банк операцияләре башкаруга гамәлдәге лицензиясе булган кредит оешмасы лизинг бирүченең устав капиталындагы өлешләрнең илледән артыгы катнашу.

Лизинг бирүченең әлеге таләпләргә туры килүен раслаучы документлар ел саен лизинг бирүче тарафыннан Вәкаләтле оешмага тапшырыла.

Әлеге таләпләргә туры килүен раслау нәтиҗәләре буенча, лизинг бирүче Вәкаләтле оешма һәм Вәкаләтле орган белән мәгълүмати хезмәттәшлек турында өч яклы килешү төзи.

Вәкаләтле оешмага әлеге таләпләргә туры килүен раслаучы документларны тапшырмаган лизинг компанияләре белән лизинг шартнамәләрен төзегән мөрәҗәгать итүчегә бәйге нигезендә сайлап алуга рөхсәт бирүдән баш тартылачак.

7.3. Субсидияләр бизнес-проектны тормышка ашыручы һәм икътисадый эшчәнлек төрләренең түбәндәге төркемнәре һәм төркемчәләре буенча төп һәм (яки) эшчәнлек алып баручы эшкуарлык субъектларына (техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2014 елның 31 гыйнварындагы 14-С номерлы боерыгы белән кабул ителгән Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД 2) ОК 029-2014 (КДЕС Ред. 2) нигезендә) бирелә:

| | |
|---|---|
| 01.1 | Берьеллык культуралар үстерү |
| 01.2 | Күпьеллык культуралар үстерү |
| 01.3 | Үсентеләр үстерү |
| 01.4 | Терлекчелек |
| 01.5 | Катнаш авыл хуҗалыгы |
| 02.1 | Урманчылык һәм башка урман хуҗалыгы эшчәнлеге |
| 02.2 | Агач әзерләү |
| 02.3 | Азык-төлек урман ресурсларын, агач булмаган урман ресурсларын һәм дару үләннәрен җыю һәм әзерләү |
| 03.2 | Балыкчылык |
| 10 | Азык-төлек продуктлары җитештерү |
| 11 | Эчемлекләр җитештерү |
| 13 | Текстиль эшләнмәләр җитештерү |
| 14 | Кием җитештерү |
| 15 | Тире һәм тире эшләнмәләре җитештерү |
| 16 | Агач эшкәртү, агачтан һәм бөкеләрдән эшләнмәләр җитештерү, җиһаздан тыш, саламнан һәм үрү өчен материаллар җитештерүдән тыш |
| 17 | Кәгазь һәм кәгазь эшләнмәләр җитештерү |
| 20 | Химия матдәләре һәм химия продуктлары җитештерү |
| 21 | Дару чаралары һәм медицина максатларында кулланыла торган материаллар җитештерү |
| 22 | Резин һәм пластмасса эшләнмәләр җитештерү |
| 23 | Металл булмаган башка минераль продукция җитештерү |
| 24 | Металлургия җитештерүе |
| 25 | Машиналар һәм җиһазлардан тыш, әзер металл эшләнмәләр җитештерү |
| 26 | Компьютерлар, электрон һәм оптик эшләнмәләр җитештерү |
| 27 | Электр җиһазлары җитештерү |
| 28 | Башка төркемнәргә кертелмәгән машиналар һәм җиһазлар җитештерү |

| | |
|---|---|
| 29 | Автотранспорт чаралары, тагылмалар һәм ярымтагылмалар җитештерү |
| 30 | Башка транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү |
| 31 | Җиһаз җитештерү |
| 32 | Башка әзер эшләнмәләр җитештерү |
| 38 | Калдыкларны җыю, эшкәртү һәм утильләштерү; икенчел чималны эшкәртү |
| 39 | Пычрату нәтиҗәләрен бетерү өлкәсендә хезмәт күрсәтү һәм калдыкларны бетерү белән бәйле башка хезмәтләр күрсәтү |
| 49.31 | Коры җирдә пассажирлар транспорты эшчәнлеге: шәһәр эчендә һәм шәһәр читендә пассажирларны ташу (табигый газда (метанда) эшләүче автотранспорт чаралары сатып алынган очракта) |
| 49.41 | Автомобиль йөк транспорты эшчәнлеге (табигый газда (метанда) эшләүче автотранспорт чаралары сатып алынган очракта) |

7.4. Лизинг шартнамәсе предметы - «Амортизация төркемнәренә кертелә торган төп чараларны классификацияләү турында» 2002 елның 1 гыйнварындагы 1 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган амортизация төркемнәренә кертелә торган төп чараларны классификацияләүнең икенче һәм аннан югарырак булган төренә кергән җиһазлар, җайланмалар, механизмнар, транспорт чаралары (җиңел автомобильләр һәм һава судноларыннан тыш), станоклар, приборлар, аппаратлар, агрегатлар, установкалар, машиналар булырга мөмкин.

Лизинг шартнамәсе предметы була алмый:

эшкуарлык субъектлары тарафыннан күпләп һәм ваклап сату эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җиһаз;

элек эксплуатацияләнгән җиһазлар.

7.5. Субсидия күләме:

а) эшкуарлыкны башлап җибәрүче субъектлар өчен субсидия лизинг шартнамәсе суммасыннан 45 проценты күләмендә, җиһаз лизингы шартнамәсе төзегәндә, беренче взносны (авансны) түләүгә максатчан чыгымнарны өлешләп финанслау шартларында бирелә, ләкин бер алучыга 1 млн сумнан да артмый;

б) эшкуарлыкның гамәлдәге субъектлары өчен субсидия лизинг шартнамәсе буенча аванс түләвен түләү буенча фактта тотылган чыгымнарны кайтаруга, лизинг шартнамәсе суммасының 30 проценты күләмендә, ләкин бер алучыга 3 млн сумнан да артмаган күләмдә бирелә;

в) гамәлдәге эшмәкәрлек субъектлары - «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыгына мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибе нигезендә, Татарстан

Республикасы Икътисад министрлыгында аккредитация алган сәнәгать мәйданчыклары резидентлары, режим объектларының җитештерү мәйданчыклары өчен лизинг шартнамәсе буенча аванс түләвен түләү буенча фактта тотылган чыгымнарны каплауга субсидия лизинг шартнамәсе суммасының 50 процентыннан да ким булмаган күләмдә һәм бер алучыга 3 млн сумнан да артмаган күләмдә бирелә.

7.6. Субсидия алуга дәгъва кылучы эшкуарлык субъекты, әлеге бүлек таләпләре нигезендә, гариза биргәндә, әлеге тәртипнең 4.1. пунктында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә түбәндәге документлар тапшыра:

эшкуарлыкны башлап җибәрүче субъектлар өчен:

лизинг шартнамәсенең төп параметрларын күрсәтеп, субсидия бирү шарты белән лизинг шартнамәсе төзү турында лизинг бирүче имзалаган гарантия хаты;

бизнес-проектны гамәлгә ашыруга кагылышлы документлар:

бина яки җир кишәрлекләре булуны раслый торган документлар күчермәләре;

проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле гамәлдәге контрактларның күчермәләре (булганда);

лицензияләр һәм рөхсәтләр, патентлар, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләре нәтиҗәләре, эксперт бәяләмәләре һ. б. күчермәләре (булганда);

әлеге тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә бизнес-проект паспорты;

эшкуарлыкның гамәлдәге субъектлары өчен:

лизин бирүче раслаган күчермәләр:

төп параметрларны күрсәтеп, төзелгән лизинг шартнамәсе,

җиһазлар сату-алу шартнамәсе һәм эшкуарлык субъекты раслаган түләү турында банк тамгасы белән лизинг шартнамәсе буенча аларга аванс күчерү хакында түләү йөкләмәсе күчермәсе (булганда);

бизнес-проектны гамәлгә ашыруга кагылышлы документлар:

бина яки җир кишәрлекләре булуны раслый торган документлар күчермәләре;

проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле гамәлдәге контрактларның күчермәләре (булганда);

лицензияләр һәм рөхсәтләр, патентлар, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләре нәтиҗәләре, эксперт бәяләмәләре һ. б. күчермәләре (булганда).

7.6.1. Сәнәгать мәйданчыгы резидентлары әлеге тәртипнең 4.1 һәм 7.6 пунктларында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә түбәндәге документларны тапшыралар:

сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшчәнлек алып бару буенча сәнәгать мәйданчыгы идарәче компаниясе белән төзелгән килешүнең күчермәсе яисә идарәче компаниянең гариза бирүченең сәнәгать мәйданчыгы резиденты булуын раслый торган хаты (резидентлар реестрыннан өземтә);

субсидия бирелгән очракта, бер календарь ел дәвамында сәнәгать мәйданчыгы территориясендә резидент тарафыннан җиһазларны урнаштыру һәм куллану турын-да гарантия хаты.

7.6.2. Режимлы объектларның җитештерү мәйданчыклары резидентлары әлеге Тәртипнең 4.1, 7.6. пунктларында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә биз-

нес-проектны гамәлгә ашыручы эшкуарлык субъектын Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәү Федераль хезмәте идарәсенә караган режимлы объектның җитештерү мәйданчыгында урнаштыру турында хат-хәбәрнамә тапшыралар.

7.7. Әлеге бүлек таләпләре нигезендә субсидия алуга дәгъва кылучы эшкуарлык субъекты әлеге Тәртипнең 6.2 пунктында каралган тәртиптә Вәкаләтле органга түбәндәге документлар тапшыра:

лизинг бирүче раслаган лизинг шартнамәсе һәм аванс түләүләрен түләү өчен счет (эшмәкәрлекне башлап җибәрүче субъектлар өчен) күчермәләре;

лизинг бирүче раслаган лизинг шартнамәсе, аванс түләүләрен түләү фактын раслаучы документлар (түләү турында банк тамгасы белән түләү йөкләмәләре, түләү таләпләре яки түләү фактын раслаучы башка документлар (банк хезмәткәре имзасы белән банк штампы) (эшкуарлыкның гамәлдәге субъектлары өчен);

лизинг килешүенең, аванс түләүләрен түләү фактын раслаучы документлар күчермәләре (түләү таләпләре, түләү фактын раслаучы башка документлар (банк хезмәткәре имзасы белән банк штампы);

әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә, вәкаләтле затның имзасы һәм эшкуарлык субъекты мөһере (юридик затлар өчен) белән расланган (Россия Федерациясе законнары белән мөһер булу бурычы билгеләнгән очракларда) яисә үз кулы белән расланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) мөрәҗәгать итүченең әлеге тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында гарантия хаты.

## 8. Социаль эшкуарлыкны үстерү

8.1. Чараның максаты – социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү һәм аларны үстерү.

8.2. Тәэмин итү чыганаклары субсидия булган чыгымнар юнәлеше булып, җиһаз, махсус инвентарь, оргтехника һәм программа чаралары (алга таба – товар) сатып алуга чыгымнар, бизнес-проект юнәлешенә туры китереп җитештерүне проектлау, дизайн, сертификацияләү һәм стандартлаштыру, персоналны укыту һәм әзерләү (алга таба – хезмәт күрсәтү) чыгымнары тора.

8.3. Субсидияләр түбәндәге шартларның берсен үтәүне тәэмин итүче эшкуарлык субъектларына бирелә:

8.3.1. Эшмәкәрлек субъектлары хезмәткәрләре арасында түбәндә күрсәтелгән гражданнар категориясенең исемлек буенча уртача саны кимендә 50 процент тәшкил итә, ә мондый хезмәткәрләрнең хезмәт хакы фондындагы өлеше – 25 проценттан да ким түгел:

инвалидлар,

өлкән яшьтәге гражданнар (60 яшьтән өлкәнрәк ир-атлар һәм 55 яшьтән өлкәнрәк хатын-кызлар);

7 (җиде) яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызлар;

ятимнәр;

балалар йортларын тәмамлаучылар;

конкурс сайлап алуны үткәрү датасына кадәр 2 (ике) ел дәвамында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар.

8.3.2. Социаль эшкуарлык субъекты түбәндәге өлкәләрдә хезмәт күрсәтү (товарлар җитештерү, эшләр башкару) эшчәнлеген башкара:

- социаль якланмаган гражданнар төркемнәренә караган затларның мәшгульлегенә һәм үзмәшгульлегенә булышлык итүне дә кертеп, һөнәри ориентациягә һәм эшкә урнашуга булышлык күрсәтү;

- социаль якланмаган гражданнар төркемнәренә керүче затларга һәм балалы гаиләләргә сәламәтлек саклау, физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтү, балалар һәм яшьләр түгәрәкләрендә, секцияләрдә, студияләрдә дәресләр үткәрү;

